Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

5 февраль 2021 ел № 6/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медальне гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге Карар рәсми басылып чыгарга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы аппаратына йөкләргә.

Глава Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан, Председатель
Совета Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан: М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советының 2021 елның
5 февралендәге 6/2 номерлы
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль Дәүләт бүләге булып тормый. Ул Татарстан Республикасының һәм Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән, халыкка рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия биргән һәм Татарстан Республикасы алдындагы башка казанышлары өчен бүләкләү формасы булып тора.

Истәлекле медаль белән Россия Федерациясе гражданнары, җәмәгать танылуы алган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан багышланган бәйрәм тантаналары һәм чараларның мактаулы кунаклары, халыклар мәдәниятләрен якынайту һәм үзара баету буенча нәтиҗәле эшчәнлеге, милләтара мөнәсәбәтләрне ныгыту, тышкы икътисадый элемтәләрне үстерүдәге казанышлары өчен бүләкләнә.

Истәлекле медаль белән бүләкләү турындагы карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы тарафыннан үз инициативасы буенча да, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдиме буенча да кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә. Истәлекле медаль, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы кул куйган таныклык һәм герб мөһере белән таныклана.

Истәлекле медальне һәм таныклыкларны тапшыру тантаналы шартларда, шул исәптән муниципаль бәйрәм чаралары кысаларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы яки аның кушуы буенча башка затлар тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы бүләкләгән очракта, таныклыкка Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы урынбасары кул куя.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле районы оешуга 90 ел
тулу уңаеннан истәлекле
медаль турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел уңаеннан истәлекле медальнең диаметры 31 мм тәшкил итә. Билгенең алгы ягында, үзәктә - диаметры 22 мм булган әйләнә буенча кабарынкы кант белән аерып алынган Чүпрәле муниципаль районы гербы сурәте. Билге әйләнәсе буенча: сулда - "ДРОЖАНОВСКИЙ РАЙОН", уңда -"ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ" язулары, аста - "1930", "90", "2020" дип язылган. Барлык сурәтләр һәм язмалар рельефлы.

Истәлекле медаль Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы флагы төсләрендәге тасма белән бизәлгән.

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы оешуга 90 ел уңаеннан истәлекле медаль күкрәкнең уң ягында, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булганда, алардан түбәнрәк урнаштырыла.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле районы оешуга 90 ел
тулу уңаеннан истәлекле
медаль турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

| | |
|---|---|
| ПАМЯТНАЯ МЕДАЛЬ<br>к 90-летию со дня образования<br>Дрожжановского района<br>Республики Татарстан<br><br>*изображение*<br>*памятной медали* | Герб Дрожжановского муниципального района<br>Республики Татарстан<br><br>УДОСТОВЕРЕНИЕ<br><br>к ПАМЯТНОЙ МЕДАЛИ<br>к 90-летию со дня образования<br>Дрожжановского района<br>Республики Татарстан |
| ______________________________<br>фамилия<br>______________________________<br>имя<br>______________________________<br>отчество<br><br>Удостоверение N 000 | награжден (а)<br><br>ПАМЯТНОЙ МЕДАЛЬЮ<br>к 90-летию со дня образования<br>Дрожжановского района<br>Республики Татарстан<br><br>Глава Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан<br>___________________________<br>подпись, инициалы, фамилия<br><br>Распоряжение Главы Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан<br>от "___"______ 20__ г. N ______ |